СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ш.Маннура ур., 72а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-44; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
№3-36

Решение
19.07.2024 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 июнендәге 5-24 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы, «Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы “Олыяз авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы **карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советының 2023 елның 13 июнендәге «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 5-24 номерлы карарына (алаг таба-карар) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктчаны өстәргә:

«5) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларның 2024 елның 1 гыйнварына 500 сумнан артмаган бурычы булу.».

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башлыгы,
Олыяз авыл җирлеге Советы рәисе /И.Я.Хаев/